**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«13 » сентябрь 2025 ел № 8

Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында

«Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын карап тотуга, шул исәптән аларны йөртүгә карата өстәмә таләпләр раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 11 августындагы 971 номерлы карары, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге уставы нигезендә, йорт хайваннарын йөртү өчен гражданнарның, хайваннарның иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәте сакланышын тәэмин итүче шартлар тудыру максатында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. Йорт хайваннарын йөртү өчен рөхсәт ителгән урын (урыннар) итеп билгеләргә:

- Боерган авылында 16:39:191001:3 кадастр номерлы җир кишәрлеге;
- Колыш авылында 16:39:190801:7 кадастр номерлы җир кишәрлеге;
- Таулар авылында 16:39:190601:2 кадастр номерлы җир кишәрлеге;
- Туера авылында 16:39:190901:18 кадастр номерлы җир кишәрлеге;

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карар үтәлешен кнтрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Г.Г.Минакова